ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО БИОЛОГИЧЕСКИМ РЕСУРСАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ БИОЛОГИК РЕСУРСЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**Приказ** **Боерык**

30.03.2018 г. Казань № 79-од

Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәти тәртип таләпләрен саклау һәм ихтыяҗлар бәрелешен хәл итү буенча комиссия турындагы Кагыйдәнамәне раслау турында

2004 елның 27 июленнән № 79-ФЗ "Россия Федерациясенә дәүләт гражданлык хезмәте күрсәтү турында"гы федераль канун,2008 елның 25 декабреннән 273-ФЗ номерлы "Коррупциягә каршылык күрсәтү" турындагы Федераль канун, 2010 елның 1 июленнән 821 номерлы "Федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәти тәртип таләпләрен саклау һәм ихтыяҗлар бәрелешен хәл итү буенча комиссияләр турында"гы Россия Федерациясе Президенты Боерыгы, 2006 елның 4 маеннан 34-ЗРТ номерлы "Татарстан Республикасында коррупциягә каршылык күрсәтү" турындагы Татарстан Республикасы кануны, 2010 елның 25 августыннан УП-569 номерлы "Татарстан Республикасында дәүләт хезмәткәрләренең хезмәти тәртип таләпләрен саклау һәм ихтыяҗлар бәрелешен хәл итү буенча комиссияләр турында"гы Татарстан Республикасы Кануны белән тәңгәл килеп **боерам:**

1. Кушымтада бирлгән Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәти тәртип таләпләрен саклау һәм ихтыяҗлар бәрелешен хәл итү буенча комиссия турындагы Кагыйдәнамәне расларга.
2. Татарстан Республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсенең 2015 елның 2 июленнән 84-од номерлы "Татарстан Республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсенеңдә дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәти тәртип таләпләрен саклау һәм ихтыяҗлар бәрелешен хәл итү буенча комиссия турында", 2016 елның 25 мартыннан 45-од номерлы "Татарстан Республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсенең 2015 елның 2 июленнән 84-од номерлы "Татарстан Республикасының хайваннар дөньясы объектларын

саклау һәм алардан файдалану идарәсенендә дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәти тәртип таләпләрен саклау һәм ихтыяҗлар бәрелешен хәл итү буенча комиссия турында"гы боерыгына үзгәрешләр кертү турында"гы боерыкларын көчен югалткан дип санарга.

3. Боерыкның үтәлүе артыннан тикшерүне Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары Ю.Б.Матвеевка тапшырам.

Рәис Ф.С.Батков

2018 елның 30 мартыннан 79-од номерлы
Татарстан Республикасының Биологик
ресурслар буенча дәүләт комитеты
боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәти тәртип таләпләрен саклау һәм ихтыяҗлар бәрелешен хәл итү буенча комиссия турындагы Кагыйдәнамә

## 1. Гомуми кагыйдәләр

1.1. Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәти тәртип таләпләрен саклау һәм ихтыяҗлар бәрелешен хәл итү буенча комиссия турындагы Кагыйдәнамә (алга таба – Кагыйдәнамә) 2004 елның 27 июленнән № 79-ФЗ “Россия Федерациясенә дәүләт гражданлык хезмәте күрсәтү турында”гы федераль канун, 2008 елның 25 декабреннән № 273-ФЗ “ Коррупциягә каршылык күрсәтү турында”гы федераль канун, 2010 елның 1 июленнән № 821 “Федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәти тәртип таләпләрен саклау һәм ихтыяҗлар бәрелешен хәл итү буенча комиссияләр турында”гы Россия Федерациясе Президенты Боерыгы, 2003 елның 16 гыйнварыннан № 3-ЗРТ “Татарстан Республикасына дәүләт гражданлык хезмәте күрсәтү турында”гы Татарстан Республикасы Кануны, 2010 елның 25 августыннан УП-569 номерлы “Татарстан Республикасында дәүләт хезмәткәрләренең хезмәти тәртип таләпләрен саклау һәм ихтыяҗлар бәрелешен хәл итү буенча комиссияләр турында”гы Татарстан Республикасы Президенты Боерыгы нигезендә эшкәртелде.

Кагыйдәнамә белән Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәти тәртип таләпләрен саклау һәм ихтыяҗлар бәрелешен хәл итү буенча комиссиянең (алга таба – Комиссия)формалашу һәм эшчәнлек тәртибе билгеләнә.

1.2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе, федераль кануннар, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы кануннары һәм бу кагыйдәнамә белән җитәкчелек итә.

1.3.Комиссиянең төп максаты булып булышлык тора:

Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында дәүләт гражданлык хезмәткәрләре белән (алга таба - дәүләт хезмәткәрләре) чикләүләрне һәм тыюларны, ихтыяҗлар бәрелешен булдырмау һәм хәл итү турында таләпләрне саклауны тәэмин итүгә, ә шулай ук алар белән, 2008 елның 25 декабреннән № 273-ФЗ “Коррупциягә каршылык күрсәтү турында”гы федераль канун, башка федераль кануннар белән билгеләнгән вазыйфаларны башкаруны

тәэмин итүдә (алга таба- хезмәти тәртипкә таләпләр һәм (яки) ихтыяҗлар бәрелешен хәл итү турында таләпләр);

Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында коррупцияне кисәтү буенча чаралар уздыруда.

1.4. Комиссия, Комитетта Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфаларын алмаштыручы (алга таба – гражданлык хезмәте вазыйфалары), дәүләт хезмәткәрләренә карата (чыгарма артыннан, Татарстан Республикасы Президенты һәм Министрлар Кабинеты белән билгеләнә торган һәм алардан азат ителә торган вазыйфаларда, гражданлык хезмәте вазыйфаларын алмаштыручы Комитет рәисе урынбасары) хезмәти тәртип таләпләрен һәм (яки) ихтыяҗлар бәрелешен хәл итү таләпләрен тоту белән бәйле сорауларны карый.

1.5. Комитетта, Татарстан Республикасы Президенты һәм Министрлар Кабинеты белән билгеләнә торган һәм алардан азат ителә торган вазыйфаларда, Татарстан Республикасының гражданлык хезмәте вазыйфаларын алмаштыручы дәүләт хезмәткәренә карата хезмәти тәртип таләпләрен һәм (яки) ихтыяҗлар бәрелешен хәл итү таләпләрен тоту белән бәйле сорауларны, Татарстан Республикасы Президенты Аппаратында һәм Татарстан Республикасының Министрлар Кабинеты Аппаратында оештырылган дәүләт гражданлык хезмәткәренең хезмәти тәртип таләпләрен саклау һәм ихтыяҗлар бәрелешен хәл итү буенча комиссия карый.

1.6. Комиссия җинаять эшләре һәм административ хокук бозуларны, ә шулай ук аноним хәбәрләрне карамый, хезмәт тәртибен бозу очраклары буенча тикшерүләр уздырмый.

## II. Комиссия катнашмасы

2.1. Комиссия катнашмасы Комитетның боерыгы белән раслана. Комиссия катнашмасына комиссия әгъзалары саныннан Комитет рәисе белән билгеләнә торган комиссия рәисе, комиссия рәисе урынбасары, сәркатип һәм комиссия әгъзалары керә. Барлык комиссия әгъзалары да карар кабул ителгәндә тигез хокукка ия. Комиссия рәисе булмаган вакытта, аның вазыйфаларын комиссия рәисе урынбасары башкара.

2.2. Комиссия катнашмасына керәләр:

а) Комитет рәисе урынбасары (комиссия рәисе), хокукый эш буенча алдынгы киңәшче, Комитетның дәүләт хезмәте һәм кадрлар секторы мөдире, коррупцияне һәм башка хокук бозуларны булдырмау эше өчен җаваплы зат (комиссия сәркатибе), Комитетның структур бүлекчә җитәкчеләре, Комитет рәисе белән билгеләнә торган, Комитеттагы бүлекчәләрнең дәүләт хезмәткәрләре;

б) коррупциягә каршы сәясәт сораулары буенча Татарстан Республикасының Президент Идарәсе вакиле һәм (яки) дәүләт хезмәте һәм кадрлар сораулары буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының бүлекчәсе вәкиле;

в) эшчәнлекләре дәүләт хезмәте белән бәйле, гыйльми оешмалар, һөнәри белем бирү оешмалары, югары һәм өстәмә белем бирү оешмаларыны вәкиле (вәкилләре);

2.3. Комитет рәисе, Комиссия катнашмысына Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты карамагындагы Иҗтимагый киңәшмә вәкилләрен кертү турында карар кабул итәргә мөмкин.

2.4. Бу Кагыйдәнамәнең 2.2. пунктының «б», «в» кече пунктларында һәм 2.3. пунктында күрсәтелгән затлар, билгеләнгән тәртиптә, туры килүче әгъзалар һәм оешмалар белән тәңгәл китереп, Комитет рәисе соравы нигезендә комиссия катнашмасына кертеләләр. Яраштыру мөрәҗәгать кергән көннән алып 10 көн эчендә үтәлә.

2.5. Комитетта дәүләт хезмәте вазыйфаларын алмаштырмаган комиссия әгъзалары, комиссия әгъзаларының гомуми саныннан дүрттән бер өлешеннән дә ким булмаска тиеш.

2.6. Комиссия катнашмасы, аның карарына йогынты ясый торган, ихтыяҗлар бәрелеше очрагын кисәтерлек итеп формалаштырыла.

2.7. Комиссия утырышында киңәш бирү хокукы белән катнашалар:

а) аңа карата комиссия белән хезмәти тәртип таләпләрен саклау һәм ихтыяҗлар бәрелешен хәл итү соравы карала торган, дәүләт хезмәткәренең турыдан – туры җитәкчесе, һәм комиссия рәисе белән билгеләнә торган, Идарәдә, комиссия белән бу сорау карала торган, дәүләт хезмәткәре алып тора торган вазыйфа буенча, шул ук вазыйфаны үти торган ике дәүләт хезмәткәре;

б) Идарәдә дәүләт хезмәте вазыйфасын алмаштырган, башка дәүләт хезмәткәрләре; дәүләт хезмәте сораулары буенча һәм комиссия белән карала торган сораулар буенча аңлатмалар бирә алучы белгечләр;

башка дәүләт әгъзаларының, җирле үзидарә агъзаларының вазыйфаи затлары; аларның эшләре белән кызыксынучы оешма вәкилләре; граждан хезмәткәренең язмача гаризасы нигезендә, комиссия рәисе карары буенча, комиссия утырышына 3 көн кала, һәрбер конкрет очракта аерым, комиссия белән хезмәти тәртип таләпләрен саклау һәм ихтыяҗлар бәрелешен хәл итү соравы карала торган дәүләт хезмәткәренең вәкиле.

2.8. Комиссия утырышында катнашучы әгъзаларының саны, барлык әгъзаларның гомуми санының өчтән икесеннән дә ким булмаса, комиссия утырышы хокуклы дип санала. Идарәдә дәүләт хезмәте вазыйфасын алмаштыручы, комиссия әгъзалары катнашуында гына комиссия утырышын алып бару ярамый.

2.9. Комиссия әгъзасының, комиссия утырышының көн тәртибенә кертелгән, сорауны караганда ихтыяҗлар бәрелешенә китерергә мөмкин булган,туры яки турыдан-туры булмаган шәхси кызыксынуы булса, ул утырыш башланыр алдыннан аның турыда хәбәр итәргә тиеш. Андый очракта, ул комиссия әгъзасы утырышта катнашмый.

## III. Комиссиянең эш тәртибе

15. Комиссия утырышын җыю өчен нигезләр:

а) Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары белән тәңгәл килеп уздырылган, дәүләт хезмәткәрләренә бирелә торган мәгълүматның тулылыгын һәм дөреслеген тикшерү нәтиҗәләре буенча һәм дәүләт

хезмәткәрләре белән  хезмәти тәртипне тотуларын тикшерү буенча, шаһит була торган тикшерү материаллары белән, Комитет рәисенең таныштыруы:

2009 елның 30 декабреннән № УП-702 Татарстан Республикасы Президентының  Боерыгы белән расланган, Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтендәге  урынны алмаштырырга теләүче гражданнар белән үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм милки характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, ә шулай ук Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләре белән үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм милки характердагы йөкләмәләре турында  мәгълүмат бирү турындагы Кагыйдәнамә белән каралган, дәүләт хезмәткәре белән бирелә торган мәгълүматның тулылыгы һәм дөреслеге турында;

дәүләт хезмәткәре белән хезмәти тәртип  таләпләрен һәм (яки) ихтыяҗлар бәрелешен хәл итү буенча таләпләрне тотмау турында;

б) Комитетның, дәүләт хезмәте һәм кадрлар секторындагы коррупцияне һәм башка хокук бозуларны булдырмау эше өчен җаваплы затка кергән, Комитетның норматив хокукый гамәлләре белән билгеләнгән тәртиптә:

Комитетта Татарстан Республикасының дәүләт гражданнар хезмәте вазыйфалары исемлегенә кертелгән,  аларны алмаштыручы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре үзенең, ә шулай ук ире (хатыны) һәм яше җитмәгән балаларының керемнәре, мөлкәте һәм милки характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле, Комитетта дәүләт хезмәте вазыйфасын алмаштырган гражданның, әгәр дә бу оешманы җитәкләүнең аерым функцияләре, аның хезмәти вазыйфаларына кергән булса, дәүләт хезмәтеннән киткәннән соң ике ел эчендә, коммерцияле яки коммерциясез оешмадагы вазыйфаларны алмаштырырга, яки  коммерцияле яки коммерциясез оешмада гражданлык-хокукый килешүнамә шартларында эш башкаруга рөхсәт бирү турында мөрәҗәгате;

дәүләт хезмәткәренең, объектив сәбәпләр буенча, үзенең, ә шулай ук ире (хатыны) һәм яше җитмәгән балаларының керемнәре, мөлкәте һәм милки характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирә алмау турында  гаризасы;

2013 елның 7 маеннан 79-ФЗ номерлы "Аерым дәрәҗәдәге затларга счетлар (вкладлар) ачарга һәм булдырырга, кулда булган акчаны һәм кыйммәтле әйберләрне, Россия Федерациясе территориясе чиге артында урнашкан, чит ил банкларында тотарга,  чит ил финанс кораллары белән кулланырга һәм ( яки) ия булырга тыю турында"гы Федераль канунның таләпләрен,счетлар( вкладлар), кулда булган акча һәм кыйммәтле әйберләр саклана торган, чит ил финанс кораллар һәм ( яки) ия булган  чит ил банкы урнашкан ,чит ил территориясендә, чит ил кануннары белән туры килеп, чит ил махсус әгъзалары белән салынган кулга алу, идарә итүне тыю сәбәпле, яки аның ихтыяҗыннан яки аның ире( хатыны) һәм яше тулмаган балалары ихтыяҗыннан тормаган, башка вакыйгалар белән бәйле рәвештә  үти алмау турында дәүләт хезмәткәренең гаризасы.

дәүләт хезмәткәренең вазыйфаи бурычларын үтәгәндә, ихтыяҗлар бәрелешенә китерә торган яки китерергә мөмкин булган, шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында белдерүе;

в) дәүләт хезмәткәре белән хезмәти тәртип  таләпләрен һәм (яки) ихтыяҗлар бәрелешен хәл итү таләпләрен тәэмин итүгә кагылышлы, яки Комитетта

коррупциягә каршы чараларны булдыру турында, Комитет рәисенең яки башка комиссия әгъзасының таныштыруы;

г) 2012 елның 3 декабреннән 230-ФЗ номерлы "Дәүләт вазыйфаларын алмаштыра торган затларның һәм башка затларның чыгымнарының керемнәренә туры килүе артыннан тикшерү турында"гы Федераль канунның 3 маддәсе 1 бүлеге белән каралган, дәүләт хезмәткәре белән дөрес яки тулы булмаган мәгълүматлар бирү турында шаһит була торган, тикшерү әсбаплары белән Комитет рәисенең таныштыруы;

д) 2008 елның 25 декабреннән 273-ФЗ номерлы "Коррупциягә каршылык күрсәтү турында"гы Федераль канун һәм Россия Федерациясенең Хезмәт кодексының 64.1маддәсе белән тәңгәл килеп, Комитетта дәүләт хезмәте вазыйфасын алмаштырган граждан белән, әгәр дә, аның дәүләт идарәсендә аерым эшләре Комитетта вазыйфаны алмаштырган вакытта үтәлгән вазыйфаи (хезмәти) бурычларына кергән булса, күрсәтелгән гражданга Комиссия белән элек бу оешма белән хезмәти яки гражданлык-хокукый мөнәсәбәтенә керү рөхсәт ителмәсә, яки андый гражданинга коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешмада вазыйфаны алмаштырырга яки коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешма белән хезмәти яки гражданлык-хокукый килешүнамә төзү шартларында эшләргә рөхсәт бирү соравы каралмаса, Комитетка коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешманың, эш үтәүгә (хезмәт күрсәтүгә) хезмәти яки гражданлык-хокукый килешүнамә төзү турында кергән белдерү кәгазе.

3.2. Кагыйдәнамәнең 3.1 пункты "б" кече пунктының икенче кызыл юлында күрсәтелгән мөрәҗәгать, Комитетта дәүләт хезмәте вазыйфасын алмаштырган граждан белән, Комитетның дәүләт хезмәте һәм кадрлар секторына, коррупцияне һәм башка хокук бозуларны булдырмау эше өчен җаваплы затка бирелә. Мөрәҗәгатьтә гражданинның исеме, фамилиясе, атасының исеме, туган вакыты, адресы, дәүләт хезмәтеннән азат ителгәнгә кадәр соңгы ике ел эчендә алмаштырган вазыйфалар, коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешманың исеме, урнашу урыны, эшчәнлек үзенчәлеге, дәүләт хезмәте вазыйфасын алмаштырган вакытта үтәлгән вазыйфаи( хезмәти) бурычлар, коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешмага карата үтәлә торган дәүләт идарәсе буенча бурычлары, килешүнамә төре ( хезмәти яисә гражданлык-хокукый ), аның якынча юридик көче, килешүнамә буенча эшләнгән хезмәткә түләнә торган бәя.

Комитетның дәүләт хезмәте һәм кадрлар секторында, коррупцияне һәм башка хокук бозуларны булдырмау эше өчен җаваплы зат белән мөрәҗәгать карала, аның нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать нигезе буенча, 2008 елның 25 декабреннән 273-ФЗ номерлы" Коррупциягә каршылык күрсәтү турында"гы Федераль канунның 12 маддәсенең таләпләрен истә тотып, дәлилләнгән йомгак әзерләнә.

3.3. Кагыйдәнамәнең 3.1 пункт "б" кече пунктының икенче кызыл юлында күрсәтелгән мөрәҗәгать, дәүләт хезмәтеннән китәргә уйлый торган дәүләт хезмәткәре белән бирелергә мөмкин, һәм бу Кагыйдәнамә белән тәңгәл килеп, Комиссия белән каралырга тиеш.

3.4. Кагыйдәнамәнең 3.1. пунктының "д" кече пунктында күрсәтелгән белдерү кәгазе, коррупцияне һәм башка хокук бозуларны булдырмау эше өчен җаваплы, Комитетның дәүләт хезмәте һәм кадрлар секторының вазыйфаи заты белән карала

һәм аның белән Комитетта дәүләт хезмәте вазыйфасын алмаштырган гражданин белән, 2008 елның 25 декабреннән 273-ФЗ номерлы“ Коррупциягә каршылык күрсәтү турында”гы Федераль канунның 12 маддәсенең таләпләрен тоту турында дәлилләнгән йомгак ясала.

3.4.1. Кагыйдәнамәнең 3.1 пункт “б” кече пунктының бишенче кызыл юлында күрсәтелгән белдерү кәгазе, коррупцияне һәм башка хокук бозуларны булдырмау эше өчен җаваплы, Комитетның дәүләт хезмәте һәм кадрлар секторының вазыйфаи заты белән карала. Һәм аның белән белдерү кәгазен карау нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән җавап әзерләнә.

3.4.2. бу Кагыйдәнамәнең 3.1 пункт “б” кече пунктының икенче кызыл юлында күрсәтелгән мөрәҗәгатьне яки 3.1. пункты “б” кече пунктының бишенче кызыл юлында һәм “д” кече пунктында күрсәтелгән белдерү кәгазен карау нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән җавап әзерләгәндә, коррупцияне һәм башка хокук бозуларны булдырмау эше өчен җаваплы, Комитетның дәүләт хезмәте һәм кадрлар секторының вазыйфаи заты, мөрәҗәгать яки белдерү кәгазе биргән дәүләт хезмәткәре белән әңгәмә уздырырга, аннан язмача аңлатма алырга хокуклы.

Мәгълүматны алыр өчен, Комитет белән билгеләнгән тәртиптә дәүләт әгъзаларына, җирле үзидарә әгъзаларына һәм кызыксынган оешмаларга сорау кәгазьләре юнәлтелергә мөмкин. Мөрәҗәгать яки белдерү кәгазе, ә шулай ук нәтиҗә һәм башка материаллар, мөрәҗәгать яки белдерү кәгазе кергәннән соң, җиде эш көне эчендә Комиссия рәисенә тапшырылалар. Сорау кәгазьләре юнәлтелгән очракта мөрәҗәгать яки белдерү кәгазе, ә шулай ук нәтиҗә һәм башка материаллар, мөрәҗәгать яки белдерү кәгазе кергәннән соң, 45 көн эчендә Комиссия рәисенә тапшырылалар. Күрсәтелгән вакыт Комиссия рәисе белән озайтылырга мөмкин, ләкин 30 көннән дә артырга тиеш түгел.

3.4.3. бу Кагыйдәнамәнең 3.2, 3.4, 3.4.1 пунктлары белән каралган дәлилләнгән нәтиҗәләр, үз эченә түбәндәгеләрне кертергә тиеш:

а) бу Кагыйдәнамәнең 3.1 пункт “б” кече пунктының икенче һәм бишенче кызыл юлларында һәм “д” кече пунктында күрсәтелгән мөрәҗәгатьтә яки белдерү кәгазендә сөйләнгән мәгълүмат;

б) сорау кәгазьләре юнәлтү нәтиҗәсендә дәүләт әгъзаларыннан, җирле үзидарә әгъзаларыннан һәм кызыксынган оешмалардан алынган мәгълүмат;

в) бу Кагыйдәнамәнең 3.1 пункт “б” кече пунктының икенче һәм бишенче кызыл юлларында һәм “д” кече пунктында күрсәтелгән мөрәҗәгатьтә яки белдерү кәгазен карау буенча дәлилләнгән нәтиҗә, ә шулай ук бу Кагыйдәнамәнең 3.13, 3.15.1, 3.18 пунктлары белән тәңгәл килеп, карарларның берсен кабул итү өчен яки башка хөкем чыгарыр өчен киңәшләр.

3.5. Комиссия рәисе, Комитетның норматив хокукый актлары белән каралган тәртиптә, Комиссия утырышы уздыру өчен нигез булган мәгълүмат кергәч:

а) 10 көн эчендә комиссия утырышының вакытын билгели. Шул ук вакытта комиссия утырышы, мәгълүмат кергәннән соң, Кагыйдәнамәнең 3.6. һәм 3.7. пункта каралган очраклардан кала, 20 көннән дә соң булырга тиеш түгел;

б) аңа карата комиссия белән хезмәти тәртип таләпләрен саклау һәм ихтыяҗлар бәрелешен хәл итү соравы карала торган, дәүләт хезмәткәрен, аның вәкилен, Комиссия әгъзаларын һәм Комиссия утырышында катнашучы башка затларны,

коррупцияне һәм башка хокук бозуларны булдырмау эше өчен җаваплы, Комитетның дәүләт хезмәте һәм кадрлар секторының вазыйфаи затына кергән мәгълүмат белән танышуны оештыра;

в) Бу Кагыйдәнамәнең 2.7. пункты “б” кече пунктында күрсәтелгән затларны комиссия утырышына чакыру турындагы гаризаларны карый, аларны канәгатьләндерү ( канәгатьләндермәү) турында һәм комиссия утырышында өстәмә материалларны карау ( карамау) турында карар кабул итә.

3.6. Гаризаларны карау буенча Комиссия утырышы, кагыйдә буларак,керемнәр, милек һәм милки характердагы йөкләмәләр турында мәгълүмат бирү вакыты узганнан соң, бер айдан да соңармыйча уздырыла.

3.7. Кагыйдәнамәнең 3.1. пункты “д” кече пунктында күрсәтелгән белдерү кәгазе, кагыйдә буларак, чираттагы (планлы) Комиссия утырышында карала.

3.8. Комиссия утырышы, кагыйдә буларак, аңа карата комиссия белән хезмәти тәртип таләпләрен саклау һәм ихтыяҗлар бәрелешен хәл итү соравы карала торган, дәүләт хезмәткәре яки Комитетта дәүләт хезмәте вазыйфасын алмаштырган гражданинның үзе булган чакта алып барыла. Дәүләт хезмәткәренең, бу сорауны аннан башка каралуы турында язмача үтенече буенча, комиссия утырышы аннан башка алып барыла. Комиссия утырышында шәхси катнашырга теләве турында дәүләт хезмәткәре яки гражданин, бу Кагыйдәнамәнең 3.1. пункты “б” кече пункты белән тәңгәл килеп бирелә торган мөрәҗәгатьтә, гаризада яки белдерү кәгазендә күрсәтә.

3.8.1. Комиссия утырышлары дәүләт хезмәткәре яки гражданин булмаганда киләсе очракта уздырылырга мөмкин:

а) әгәр дә Кагыйдәнамәнең 3.1. пункты “б” кече пунктында каралган мөрәҗәгатьтә, гаризада яки белдерү кәгазендә, дәүләт хезмәткәренең яки гражданинның Комиссия утырышында шәхси катнашу турында күрсәтмәсе булмаса;

б) әгәр дә Комиссия утырышында шәхси катнашырга ниятләгән дәүләт хезмәткәре яки гражданин, тиешле рәвештә Комиссия утырышының уздырылу вакыты һәм урыны турында белдерелеп, Комиссия утырышына килмәсә.

3.9. Комиссия утырышында дәүләт хезмәткәренең һәм башка затларның аңлатмалары тыңлана (аның рөхсәтеннән), дәүләт хезмәткәренә бирелә торган дәгъвалар буенча материаллар, ә шулай ук өстәмә материаллар карала.

3.10. Комиссия әгъзалары һәм аның утырышында катнашкан затлар, комиссия утырышы барышында билгеле булган мәгълүматларны ачарга хокуклы түгел.

3.11. Кагыйдәнамәнең 3.1 пунктта “а” кече пунктының икенче кызыл юлында күрсәтелгән, сорауны карау нәтиҗәләре буенча, комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) 2009 елның 30 декабреннән № УП-702 Татарстан Республикасы Президентының Боерыгы белән расланган, Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтендәге урынны алмаштырырга теләүче гражданнар белән һәм Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләре белән үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм милки характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү турындагы Кагыйдәнамә белән каралган, дәүләт хезмәткәре белән бирелгән мәгълүматның тулы һәм ышанычлы булуын билгеләргә;

б) Кагыйдәнамәнең “а” кече пункты белән туры килеп, дәүләт хезмәткәре белән бирелә торган мәгълүматның тулы һәм ышанычлы булмавын билгеләргә.Ул очракта Комиссия Комитет рәисенә, дәүләт хезмәткәренә карата җаваплылыкның конкрет чарасын кулланырга тәкъдим итә.

3.12. Кагыйдәнамәнең 3.1. пунктта “а” кече пунктының өченче кызыл юлында күрсәтелгән, сорауны карау нәтиҗәләре буенча, комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәре белән хезмәти тәртип таләпләре һәм (яки) ихтыяжлар бәрелешен хәл итү таләпләре сакланганы турында билгеләргә;

б) дәүләт хезмәткәре белән хезмәти тәртип таләпләре һәм (яки) ихтыяжлар бәрелешен хәл итү таләпләре сакланмаганы турында билгеләргә. Ул очракта Комиссия Комитет рәисенә, дәүләт хезмәткәренә хезмәти тәртип таләпләрен һәм (яки) ихтыяжлар бәрелешен хәл итү таләпләрен бозарга ярамавы турында хәбәр итәргә һәм дәүләт хезмәткәренә карата җаваплылыкның конкрет чарасын кулланырга тәкъдим итә.

3.13. Кагыйдәнамәнең 3.1. пунктта “б” кече пунктының икенче кызыл юлында күрсәтелгән, сорауны карау нәтиҗәләре буенча, комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) әгәр дә бу оешманы җитәкләүнең аерым функцияләре, аның хезмәти вазыйфаларына кергән булса, дәүләт хезмәтеннән киткәннән соң ике ел эчендә, коммерцияле яки коммерциясез оешмадагы вазыйфаларны алмаштырырга, яки коммерцияле яки коммерциясез оешмада гражданлык-хокукый килешүнамә шартларында эш башкаруга гражданинга рөхсәт бирергә;

б) әгәр дә бу оешманы җитәкләүнең аерым функцияләре, аның хезмәти вазыйфаларына кергән булса, дәүләт хезмәтеннән киткәннән соң ике ел эчендә, коммерцияле яки коммерциясез оешмадагы вазыйфаларны алмаштырырга, яки коммерцияле яки коммерциясез оешмада гражданлык-хокукый килешүнамә шартларында эш башкаруга гражданинга рөхсәт бирмәскә, чыгарылган карарны нигезләргә;

3.14. Кагыйдәнамәнең 3.1. пунктта “б” кече пунктының өченче кызыл юлында күрсәтелгән, сорауны карау нәтиҗәләре буенча, комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәренең, үзенең, ә шулай ук ире (хатыны) һәм яше җитмәгән балаларының керемнәре, мөлкәте һәм милки характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирә алмау сәбәпләре объектив һәм мөһим булуын тану;

б) дәүләт хезмәткәренең, үзенең, ә шулай ук ире (хатыны) һәм яше җитмәгән балаларының керемнәре, мөлкәте һәм милки характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирә алмау сәбәпләре объектив һәм мөһим булмавын тану. Ул очракта Комиссия дәүләт хезмәткәренә күрсәтелгән мәгълүматларны тапшырырга тәкъдим итә;

в) дәүләт хезмәткәренең, үзенең, ә шулай ук ире (хатыны) һәм яше җитмәгән балаларының керемнәре, мөлкәте һәм милки характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирә алмау сәбәпләре объектив булмавын һәм күрсәтелгән мәгълүматларны бирмәү чарасы булып торуын тану. Ул очракта Комиссия Комитет

рәисенә, дәүләт хезмәткәренә карата җаваплылыкның конкрет чарасын кулланырга тәкъдим итә.

3.15. Кагыйдәнамәнең 3.1. пунктта “б” кече пунктының дүртенче кызыл юлында күрсәтелгән, сорауны карау нәтиҗәләре буенча, комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) 2013 елның 7 маеннан 79-ФЗ номерлы “Аерым дәрәҗәдәге затларга счетлар (вкладлар) ачарга һәм булдырырга, кулда булган акчаны һәм кыйммәтле әйберләрне, Россия Федерациясе территориясе чиге артында урнашкан, чит ил банкларында тотарга, чит ил финанс кораллары белән кулланырга һәм (яки) ия булырга тыю турында”гы Федераль канунның таләпләрен үтәргә кымачаулый торган шартлар объектив һәм мөһим булуын танырга;

б) 2013 елның 7 маеннан 79-ФЗ номерлы “Аерым дәрәҗәдәге затларга счетлар( вкладлар) ачарга һәм булдырырга, кулда булган акчаны һәм кыйммәтле әйберләрне, Россия Федерациясе территориясе чиге артында урнашкан, чит ил банкларында тотарга, чит ил финанс кораллары белән кулланырга һәм ( яки) ия булырга тыю турында”гы Федераль канунның таләпләрен үтәргә кымачаулый торган шартлар объектив һәм мөһим булмавын танырга. Ул очракта Комиссия Комитет рәисенә, дәүләт хезмәткәренә карата җаваплылыкның конкрет чарасын кулланырга тәкъдим итә.

3.15.1. Кагыйдәнамәнең 3.1. пунктта “б” кече пунктының бишенче кызыл юлында күрсәтелгән, сорауны карау нәтиҗәләре буенча, Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәре белән вазыйфаи бурычларын үтәгәндә ихтыяҗлар бәрелеше булмавын танырга;

б) дәүләт хезмәткәре белән вазыйфаи бурычларын үтәгәндә, шәхси кызыксыну ихтыяҗлар бәрелешенә китерергә мөмкин булуын танырга. Бу очракта Комиссия дәүләт хезмәткәренә һәм (яки) Комитет рәисенә ихтыяҗлар бәрелешен көйләү буенча яки аның килеп чыгуын булдырмау буенча чаралар кабул итәргә киңәш бирә;

в) дәүләт хезмәткәре ихтыяҗлар бәрелешен көйләү буенча таләпләрне тотмаган дип танырга. Ул очракта Комиссия Комитет рәисенә, дәүләт хезмәткәренә карата җаваплылыкның конкрет чарасын кулланырга тәкъдим итә.

3.16. Кагыйдәнамәнең 3.1. пунктта “в” кече пунктында күрсәтелгән, сорауны карау нәтиҗәләре буенча, Комиссия туры килүче карар кабул итә.

По итогам рассмотрения вопроса, предусмотренного подпунктом «в» пункта 3.1 настоящего Положения, Комиссия принимает соответствующее решение.

3.17. Кагыйдәнамәнең 3.1. пунктта “г” кече пунктында күрсәтелгән, сорауны карау нәтиҗәләре буенча, комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) 2012 елның 3 декабреннән 230-ФЗ номерлы “Дәүләт вазыйфаларын алмаштыра торган затларның һәм башка затларның чыгымнарының керемнәренә туры килүе артыннан тикшерү турында”гы Федераль канунның 3 маддәсе 1 булеге белән тәңгәл килеп, дәүләт хезмәткәре белән бирелгән мәгълүматлар дөрес һәм тулы булуын танырга;

б) 2012 елның 3 декабреннән 230-ФЗ номерлы “Дәүләт вазыйфаларын алмаштыра торган затларның һәм башка затларның чыгымнарының керемнәренә туры килүе артыннан тикшерү турында”гы Федераль канунның 3 маддәсе 1 булеге

белән тәңгәл килеп, дәүләт хезмәткәре белән бирелгән мәгълүматлар дөрес һәм тулы булмавын таныырга. Ул очракта Комиссия Комитет рәисенә, дәүләт хезмәткәренә карата җаваплылыкның конкрет чарасын кулланырга һәм (яки) чыгымнар артыннан тикшерү барышы нәтиҗәсендә алынган әсбапларны прокуратурага һәм (яки) вәкаләте булган башка дәүләт әгъзаларына җибәрергә тәкъдим итә.

3.18. Кагыйдәнамәнең 3.1. пунктта “д” кече пунктында күрсәтелгән, сорауны карау нәтиҗәләре буенча, Комитетта дәүләт хезмәте вазыйфасын алмаштырган гражданинга карата комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) әгәр дә, аның дәүләт идарәсе буенча аерым эшләре вазыйфаи (хезмәти) бурычларына кергән булса, коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешмада вазыйфаны алмаштырырга яки коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешма белән хезмәти яки гражданлык-хокукый килешүнамә төзү шартларында эшләргә рөхсәт бирергә;

б) аның белән коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешмада вазыйфаны алмаштыру, яки коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешма белән хезмәти яки гражданлык-хокукый килешүнамә төзү шартларында эшләү, 2008 елның 25 декабреннән 273-ФЗ номерлы “Коррупциягә каршылык күрсәтү турында”гы Федераль канунның таләпләрен бозуны билгеләргә.

3.19. Кагыйдәнамәнең 3.1. пунктта “а”, “б”, “г” һәм “д” кече пунктлары белән каралган, сорауны карау нәтиҗәләре буенча, аңа нигез булган очракта, комиссия Кагыйдәнамәнең 3.11- 3.15.1, 3.17-3.18 пунктларында каралган карарлардан башка аермалы карар чыгарырга мөмкин. Андый карар чыгаруның нигезләре һәм мотивлары комиссия утырышының беркетмәсендә чагылырга тиеш.

3.20. Комиссия карарын үтәү өчен, Комитетның боерык проектлары әзерләнергә мөмкин. Алар билгеләнгән тәртиптә Комитет рәисенә тикшерүгә тапшырылалар.

3.21. Кагыйдәнамәнең 3.1. пунктында күрсәтелгән сораулар буенча комиссия карары, серле тавыш бирү юлы белән ( әгәр дә комиссия башка карар кабул итмәсә) комиссия утырышында катнашучы әгъзаларның күпчелек тавышы белән кабул ителә.

3.22. Комиссия карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә, аларга комиссия утырышында катнашкан әгъзалар имза куя.Комиссия карарлары, Комитет рәисе өчен, тәкъдим характерында бирелэләр, чыгарма артыннан Кагыйдәнамәнең 3.1. пунктта “б” кече пунктының икенче кызыл юлында күрсәтелгән сорауны карау нәтиҗәләре буенча чыгарылган карар. Кагыйдәнамәнең 3.1. пунктта “б” кече пунктының икенче кызыл юлында күрсәтелгән сорауны карау нәтиҗәләре буенча чыгарылган карар мәҗбүри булып санала.

3.23. Комиссия утырышының беркетмәсендә күрсәтелә:

а) комиссия утырышының вакыты, комиссия әгъзаларының һәм комиссиядә булган башка затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре;

б) хезмәти тәртип таләпләрен һәм (яки) ихтыяҗлар бәрелешен хәл итү таләпләрен саклау соравы кагылган дәүләт хезмәткәренең фамилиясен, исемен, атасының исемен, дәүләт хезмәте вазыйфасын күрсәтеп, комиссия утырышында карала торган һәрбер сорауның формалаштырылуы;

в) дәүләт хезмәткәренә куела торган дәгъвалар һәм алар нигезләнә торган материаллар;

г) дәүләт хезмәткәренең яки башка затларның, бу сорауга кагыла торган, аңлатма эчтәлеге;

д) утырышта чыгыш ясаган затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре һәм чыгышларының кыскача эчтәлеге;

е) Комиссия утырышын уздыру өчен нигез булган мәгълүмат чыганагы, мәгълүматның Комитетка керү вакыты;

ж) башка мәгълүматлар;

з) тавыш бирү нәтиҗәләре;

и) карарлар һәм аларны кабул итү нигезләре.

3.24. Карар белән риза булмаган комиссия әгъзасы, үзенең фикерен язмача рәвештә бирергә хокуклы. Ул комиссия утырышының беркетмәсенә катнаштырылырга һәм дәүләт хезмәткәре аның белән таныштырылырга тиеш.

3.25. Комиссия утырышының беркетмә күчермәләре 7 көн эчендә Комитет рәисенә җибәрелә, дәүләт хезмәткәренә тулысынча яки аннан өземтәләр рәвешендә генә җибәрелә, ә шулай ук комиссия карары буенча – башка кызыксынган затларга.

3.26. Комитет рәисе комиссия утырышы беркетмәсен карап чыгарга тиеш һәм үзенең хокуклары чикләрендә, дәүләт хезмәткәренә карата, Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары белән каралган, җаваплылык чараларын кулланганда, ә шулай ук коррупциягә каршылык күрсәтү чараларын оештыруның башка сораулары буенча, анда бирелгән тәкъдимнәрне исәпкә алырга хокуклы.

Комитет рәисе, комиссиянең тәкъдимнәрен карап чыгу һәм кабул ителгән карар турында, язмача рәвештә, беркетмә кергән вакыттан алып, бер ай эчендә комиссиягә хәбәр итә. Идарә башлыгының карары якындагы утырышта хәбәр ителә һәм мәгълүмат рәвешендә тикшерүсез кабул ителә.

3.27. Әгәр дә комиссия белән дәүләт хезмәткәренең эшендә (гамьсезлектә) тәртип бозу сыйфаты ачыкланган очракта, аның турында мәгълүмат, дәүләт хезмәткәренә карата, Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары белән каралган, җаваплылык чараларын куллану турында сорауны чишү өчен, Комитет рәисенә тапшырыла.

3.28 Әгәр дә комиссия белән дәүләт хезмәткәренең эшендә (гамьсезлектә) административ хокук бозу яки җинаять эше сыйфатлары булган очрак ачыкланса, комиссия рәисе күрсәтелгән эш (гамьсезлек) турында мәгълүматны һәм ул очракны дәлилләүче документларны, өч көн эчендә , ә кирәк булса – ашыгыч рәвештә, хокук әгъзаларына тапшырырга тиеш.

3.29. Комиссия утырышының беркетмә күчермәсе яки аның өземтәсе, хезмәти тәртип таләпләрен һәм (яки) ихтыяҗлар бәрелешен хәл итү таләпләрен саклау соравы кагылган дәүләт хезмәткәренең шәхси эшенә катнаштырыла.

3.30. Комиссия сәркатибе имзасы һәм Комитет мөһере белән расланган Комиссия карарының өземтәсе,аңа карата Кагыйдәнамәнең 3.1. пункты “б” кече пунктының икенче кызыл юлында күрсәтелгән сорау карала торган, Комитетта дәүләт хезмәте вазыйфасын алмаштырган гражданинга имза астына бирелә яки Комиссия утырышыннан соң килгән, бер эш көненнән соңармыйча, белдерү кәгазе булган заказлы хат белән мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән адрес буенча җибәрелә.

3.31. Комиссия эшчәнлеген техник яктан һәм кирәкле документ белән тәэмин итү, ә шулай ук комиссия әгъзаларына, көн тәртибенә кертелгән сораулар, утырышны уздыру вакыты һәм урыны турында хәбәр итү, комиссия утырышында карала торган материаллар белән комиссия әгъзаларын таныштыру, коррупцияне һәм башка хокук бозуларны булдырмау эше өчен җаваплы, Комитетның дәүләт хезмәте һәм кадрлар секторының вазыйфаи заты белән алып барыла.